МИНИСТЕРСТВО ПРОСВЕЩЕНИЯ РОССИЙСКОЙ ФЕДЕРАЦИИ

Министерство образования и науки Республики Татарстан

Атнинский районный исполнительный комитет Республики Татарстан

Новошашинская ООШ

| РАССМОТРЕНО | СОГЛАСОВАНО | УТВЕРЖДЕНО |
|---|---|---|
| МО начальных классов | Заместитель директора по УВР | Директор школы |
| Сабирзянова Л. Р. | Курбанова Г. Ф. | Халиков И. М. |
| Протокол №1 от «25» августа 2023 г. | Протокол №1 от «26» августа 2023 г. | Приказ №89 о/д от «28» августа 2023 г. |

РАБОЧАЯ ПРОГРАММА

учебного предмета «В мире книг»

для обучающихся 3класса

с. Новые Шаши 2023

## УКЫТУНЫҢ ПЛАНЛАШТЫРЫЛГАН ПРЕДМЕТ НӘТИҖӘЛӘРЕ

**3 нче сыйныф ахырына укучылар өйрәнәчәк:**

- баланың үзенә иң ошаган авторның берничә әсәрен;
- тиешле интонация белән текстларны аңлап укый һәм укыганны үз сүзләре белән эзлекле итеп сөйли белүе;
- текстлардагы сүзләрнең күп мәгънәле, күчерелмә мәгънәдә булуларын аңлата алу;
- сурәтне (образны) әсәр текстында таба һәм кеше белән бәйләнешен күрә белү;
- “әсәр” төшенчәсен, җанлы сөйләмнән аермасын белү;
- әдәби әсәрнең чәчмә, тезмә,пьеса рәвешендә язылуы үзенчәлекләрен үзләштергән булу;
- әдәбиятның төрләрен, матур әдәбиятны аера белү;
- китаплардан, дәреслекләрдән төрле авторларның 6–8 әсәрен яттан белү;
- мөстәкыйль рәвештә китаплар сайлый белү, китап элементлары буенча аның эчтәлеген ачыклау;
- сүзлекләр белән мөстәкыйль эшләү;
  - -аңлап, йөгерек уку күнекмәләре булдыру;
  - -текстның темасын, төп фикерен табу, текстны мәгънәви кисәкләргә бүлү, текстның планын төзү, тулы һәм кыскача эчтәлекне бирә белүләренә ирешү;
  - -фольклор әсәрләрен тану, автор әсәрләре белән уртаклыгын, аермасын билгеләү;
  - әсәрдәге геройлар турында үз фикерләрен әйтә белүләренә ирешү, геройларның характерын
  - ачыклау, чагыштыру;
  - әдәби әсәрләр белән кызыксыну, эшли белү күнекмәләре булу.

**<u>Укучы эшли алырга тиеш:</u>**

- -“әсәр” төшенчәсен, җанлы сөйләмнән аермасын белергә;
- әсәрдәге сүзләрне дөрес итеп әйтеп,кычкырып һәм эчтән укый белергә;
- шигырьләрне сәнгатьле итеп укырга;
- әсәрнең мәгънәви кисәкләре арасында бәйләнешләрне ачыкларга, төп фикерне билгеләргә һәм аны үз сүзләрең белән әйтеп бирергә;
- төрле авторларның шигырен яттан сөйли белергә;
- кыска күләмле әсәрләрнең эчтәлеген сөйләргә;
- сүзлекләр белән мөстәкыйль эшләргә;
- әсәрдәге төп геройга үз мөнәсәбәтеңне белдерергә;
- фольклор әсәрләрен танырга, автор әсәрләре белән уртаклыгын, аермасын билгеләргә.

**Укучылар өйрәнергә мөмкинлек алачак:**

- сөйләм этикасын уңышлы файдалану;
- мөстәкыйль рәвештә уку өчен китап сайлау;
- иптәшеңнең эшчәнлеген бәяләү,
- үз фикереңне тулы әйтә белү;
- сүзлекләрдән кирәкле мәгълүматны таба белү, уңышлы файдалану.
- **3 нче сыйныф ахырында укучылар белергә тиеш**
- **Уку күнекмәләре.** Дөрес, аңлап, тиешле дәрәҗәдә йөгерек һәм сәнгатьле уку. Интонацияне (тизлек, логик басым, пауза, тон) текст эчтәлегенә бәһле рәвештә сайлау. Уку тизлеген сүзне тулы һәм төгәл күрергә, тиз аңларга өйрәтү исәбенә үстерү. Эчтән уку алымына зур күләмле һәм күптөрле текстларны укытып өйрәтү. Сәнгатьле уку осталыгын камилләштерү. Авазларны ачык һәм дөрес әйтүгә ирешү. Укыганда орфоэпия нормаларын үтәү, уку тизлеген эчтәлеккә бәйле рәвештә сайлау, аны арттыра һәм киметә белү, сөйләм максатыны карап, тавышны көчәйтеп

һәм пышылдап уку. Әдәби әсәрләрне рольләргә бүлеп укырга һәм сәхнәләштерергә өйрәтү.

- Сәнгатьле укуга хәзерләнә белү: эчтәлекне аңлау, сурәтләнгән күренешне ачык итеп күз алдына китерү, фраза һәм шигырь юлларының яңгырашып ишетү, ритмын отып алу, башкару максатын аңлау.
- **Текст өстендә эшләү.** Әсәрне тыңлаганда һәм укыганда төп фикерне тотып ала белү, хикәяләүнең логикасын, текстагы мәгънәви һәм интонацион бәйләнешләрне аңлау. Вакыйгаларның эзлеклелеген, үзара бәйләнешен билгеләү. Сүзле картина элементлары кертеп, укылган текстның эчтәлеген тулысынча, сайлап һәм кыскача сөйләү, җавапның дөреслеген тексттан өзекләр укып раслау. Текстны мөстәкыйль рәвештә мәгънәле кисәкләргә бүлү һәм аларда чагылдырылган төп фикерне таба алу. Укытучы ярдәмендә план төзү, эчтәлеген сөйләү. Кешеләрне, табигатьне һәм вакыйгаларны сурәтләү өчен автор кулланган сүзләрне табу. Әсәр геройларының эш-кыланышларына, уй-хисләренә һәм алар нигезендә яткан сәбәпләргә укытучы ярдәмендә бәя бирү.
- Мәктәп, сыйныф тормышында күзәтүләр нәтиҗәсендә хикәяләр төзү. Үз сөйләмеңне планлаштыра белү, соңыннан тикшерү һәм, сөйләм максатын исәпкә алып, төзәтмәләр кертү. Әкият һәм хикәяләр сюжетына үз вариантларыңны уйлап табу, әсәр геройларының урыннарының алмаштыру, аларны гадәти булмаган хәлләргә кую. Сюжет үсешен алдан билгели алу, исеме һәм башламы буенча китапның темасын, якынча эчтәлеген билгеләү.
- Балалар белергә тиешле әдәби жанрлар: әкият һәм хикәя, шигырь һәм мәсәл, халык авыз иҗаты әсәрләре (табышмак, мәкаль, җыр, әйтем, бәет).
- **Уку һәм балалар китабы белән эшләү.**
- Дәреслекнең эчтәлек өлешеннән әсәрләрне исеме буенча табу. Бер темага караган текстларны аеру.
- Тәкъдим ителгән китаплар исемлеге белән эшләү. Китап авторы белән танышу, аның исем-фамилиясен, китаптагы портретын табу; берничә китабын чагыштырып, иҗатының темасын билгеләү; авторның үзе турындагы әсәрләрен ачыклау. Укылган китап буенча әңгәмәдә катнашу, сорауны ишетү, аңлау һәм темага бәйле рәвештә җавап бирү; үз фикереңне дәлилләү өчен әсәрдән өзекләр китерә белү.
- Авторы, исеме һәм интонациясе буенча укылмаган китап турында кечкенә хикәя язу. Укылган китап турында, темасын, геройларын, вакыйгаларын чагылдырып һәм үз мөнәсәбәтеңне белдереп, 4-5 җөмләдән торган хикәя язу.

## Уку предметының эчтәлеге:

**Хайваннар турындагы әкиятләр.** Халык авыз иҗатының бер төре булган һәм җир йөзендәге барлык милләтләрдә дә яшәп килүче, буыннан буыннарга күчеп йөри торган хайваннар турындагы әкиятләргә карата гомуми күзаллау булдыру. Әкиятләрнең гасырлар дәвамында үсеше. Гади вакыт тасмасы: 1) бик борынгы әкиятләр, 2) борынгы, 3) бик борынгы булмаган әкияти вакыйгалар турында аңлату.

Бик борынгы әкиятләрдә хайваннар арасындагы мөнәсәбәтләр, аларның тышкы күренешләре төп урынны алып тора. Борынгы әкиятләрдә геройның аңы, хәйләгә осталыгына дан җырлана. Ә әкияти вакыйгалар исә үз эченә геройның изге эшләрен, аның сәләтен, киң күңеллеген күрсәтүне максат итеп куя. Йөремсәк әкиятләр турында күзаллау булдыру. *Алман халык әкияте «Сандугач белән Аю», Африка халыклары әкияте «Сырны ничек бүлгәннәр?», Әфган халык әкияте «Иң яхшы дару», Латыш халык әкияте «Шайтанга ничә яшь?*.

**Мәсәл жанры.** Мәсәлләрнең ике өлештән: хикәяләү (тарихи вакыйга) һәм

моральдән (нәтиҗә, тәрбияви аңлату) торуын аңлату. Мәсәлдәге хикәяләү өлешенең әкиятләрдән килеп чыгуына басым ясау. Мәсәлләрнең мораль өлешенең мәкальләр белән охшашлыгы. Мәсәл җанрының килеп чыгышы, үсеше. Бөтен дөньяга танылган мәсәлчеләр: Эзоп, Ж. Лафонтен, И. Крылов, татар мәсәлчеләре К. Насыйри, Г. Тукай, М. Гафури, Г. Шамуков,Т.Яхин,Ф.Яхин, Ә. Исхак һәм башка язучылар әсәрләрен өйрәнү.

*Әхмәт Исхак «Карт имән белән яшь егет» мәсәле, Габдулла Тукай «Аккош, Чуртан һәм Кыскыч», Каюм Насыйри «Комсыз эт», Нәкый Исәнбәт «Ябалак белән Чыпчык* “мәсәле.

**Мәкаль жанры.** Мәкальләр – ул борынгылар сүзе, аталар сүзе, картлар сүзе, тәҗрибә һәм хикмәт җимеше, хәтердә сакланырга тиешле хәзинә, халыкның күмәк фикере, тормыш кагыйдәсе, сүзгә дәлил, тормышта киңәш. “Мәкаль” сүзе гарәп теленнән алынган, “урынлы сүз яки тиешле урында әйтелгән сүз” дигән мәгънәне аңлатуын төшендерү. Төрле халык мәкальләре. Мәкальләрне сөйләмдә, мәсәлләрдә урынлы куллану.

**Хикәя жанры турында күзаллау формалаштыру.** Хикәя геройлары, аларның портреты һәм характер үзенчәлекләренең башкарган гамәлләре аша чагылышы. Авторның үз героена мөнәсәбәте. Геройларга чагыштырмача характеристика. Герой яшәгән тирәлек,пейзаж. *Гомәр Бәширов «Беренче кар», Абдулла Алиш «Утлы йомырка», Нәбирә Гыйматдинова «Сарбай», Галимҗан Гыйльманов «Нәсел агачы», Гәрәй Рәхим «Иске самавыр торбасы», Григорий Остер «Серне ачты», Геннадий Паушкин «Кыш», Лев Толстой «Зирәк Чәүкә»хикәяләре.*

**Әкият һәм хикәя жанрының үзгәлеге турында күзаллау формалаштыру.** Әкият һәм хикәя жанрларының композиция үзенчәлеген (күзәтүләр аша) аңлату. Укучы-тыңлауга табигый көчләрнең серен, әкият геройларының серле тормыш агышын күрсәтү, хикәя геройларының характерларында тормыштан алынган вакыйгаларны чагылдырып сөйләү. *Василий Радлов «Карганың хәйләсе», Фәнис Яруллин «Тылсымлы ачкыч».*

**Шигърият.** Кеше һәм табигать бергәлеге. Дөньяны шагыйрь күзлегеннән чыгып күзаллау. Әйләнә-тирә дөнья матурлыгы- шагыйрь өчен илһам чишмәсе булуга инандыру. Шигыйрьдә чагыштыру, сынландыру, эпитет.

Автор әсәрләрендә һәм халык авыз иҗатында охшашлык. Чагыштыру, контраст, җанландыру кебек гади әдәби алымнарны таба белү. Җанлы сөйләмнең мөһим чараларын үзләштерү күнегүләре: темп, тавыш көче, тон, сөйләм мелодикасы (тавышны күтәрү, түбәнәйтү). *Татарстан гимны, Равил Фәйзуллин «Ничек яхшы булырга?», Йолдыз «Ике җаваплы табышмак», Илдар Юзеев «Хатасыз ничек язарга?», Муса Җәлил «Яңгыр», Шәйхи Маннур «Яратам», Шәүкәт Галиев «Иншаның файдасы», «Сүзләре һәм үзләре», Йолдыз «Антенналы бәрәңге», «Спортчы Шүрәле» шигырьләре.*

**Вакыт тасмасы.** Фольклор әсәрләреннән әкиятләрне вакыт тасмасында күрсәтү (бик борынгы,борынгы,әкияти вакыйгалар )

**Библиографик культура формалаштыру.( Башка бүлекләр кысаларында тормышка ашырыла)** «Эчтәлек» бите белән танышу, аңа карап, кирәкле әсәрне китаптан таба белү, кече яшьтәге мәктәп баласының дәреслектән тыш эчтәлген оештыру: өй, мәктәп китапханәләреннән файдалану. Фән буенча сүзлек, белешмә әдәбият, вакытлы матбугат белән эшләү. Балалар китабы белән эшләү. Китапның төп өч элементын аеру: китап тышлыгы, китап төпсәсе, битләре. Китапны саклап тоту күнекмәләре булдыру. Төрле җыентыклар төзергә өйрәнү.

**Уку, сөйләү, тыңлау күнекмәләре формалаштыру**. (Барлык дәресләрдә дә тормышка ашырыла). Сәнгатьле уку күнекмәләре формалаштыру (интонация, тон, темп саклап кычкырып уку). Автор бирергә теләгән картинаны күзаллау. Эчтән укый белергә күнектерү. Чылбыр рәвешендә укыганда, үз урыныңны белеп, чират буенча уку. Укылган әсәргә анализ ясау. Уку техникасын үстерү.

ТЕМАТИЧЕСКОЕ ПЛАНИРОВАНИЕ

3 класс -34 ч.

| № | Наименование разделов и тем | Количество часов, отводимых на освоение темы | Электронные (цифровые) образовательные ресурсы |
|---|---|---|---|
| | | | |
| 1 | **Китапханәләрдән файдалана белү.** ***Эчтәлек бите белән танышу, аңа карап, кирәкле әсәрне китаптан таба белү. Б.Рәхмәт “Иң күңелле чак”.*** | **1** | |
| 2 | **Геройның эчке дөньясын аның әйләнә-тирә дөньяны танып белүе аша күрсәтү.** ***М.Галиев “Җиләктән кайтканда”. Кече яшьтәге мәктәп баласының дәреслектән тыш эчтәлген оештыру: өй, мәктәп китапханәләреннән файдалану. Төрле җыентыклар төзергә өйрәнү.*** | **1** | |
| 3 | **Шигырьләрдә чагыштыруны таба белү.** ***Китапның төп өч элементын аеру: китап тышлыгы, китап төпсәсе, битләре. Китапны саклап тоту күнекмәләре булдыру.*** ***Б.Рәхимова ”Шук болытлар,батыр җил,якты кояш”,Р.Корбан “Көз нигә моңая?”*** | **1** | |
| 4 | **Шигырьләрдә сынландыруны таба белү.** ***Шагыйрьдә чагыштыру, сынландыру, эпитет. Л.Лерон “Яңгырның ял көне”, М.Җәлил “Яңгыр” шигыре.*** | **1** | |
| 5 | **Шигырьләр аша әйләнә-тирә дөньяны табу.** ***Р.Мингалим “Август каеннары”, З. Туфайлова “Яфрак ява.” Сәнгатьле уку күнекмәләре формалаштыру ( интонация, тон, темп саклап кычкырып уку).*** | **1** | |
| 6 | **Әдәби әсәрләрнең башка сәнгать әсәрләре белән бәйләнеше.** ***М.Мазунов” Карап торам”, Г.Хәсәнов “Кыр казы”. Автор бирергә теләгән картинаны күзаллау. Эчтән укый белергә күнектерү.*** | **1** | |
| | | | |
| 7 | ***Г.Бәширов “Ана каз белән ата каз һәм аларның унике бәбкәсе”. Хикәя геройлары аларның портреты һәм характер үзенчәлекләренең башкарган гамәлләре аша чагылышы.*** | **1** | |
| 8 | ***Авторның үз героена мөнәсәбәте. Геройларга чагыштырмача характеристика Г.Остер “Серне ачты”.*** | **1** | |
| 9 | **Хикәя геройларының портретлары, характеры сөйләм һәм вакыйгалар аша чагылышы.** | **1** | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | ***Н.Гыйматдинова “Сарбай”.*** | | |
| 10 | **Кешелек дөньясы һәм тылсымлы дөнья арасындагы бәйләнеш.** ***«Иң яхшы дару» Әфган халык әкияте, “Тылсымлы китмән» Уйгур халык әкияте. Фольклор әсәрләреннән әкиятләрне вакыт тасмасында күрсәтү (бик борынгы,борынгы,әкияти вакыйгалар )*** | **1** | |
| 11 | **Хайваннар турында әкиятләр.** ***“Күрән төстәге пингвин баласы” Инглиз халык әкияте. Халык авыз иҗатының бер төре булган һәм җир йөзендәге барлык милләтләрдә дә яшәп килүче, буыннан буыннарга күчеп йөри торган хайваннар турындагы әкиятләргә карата гомуми күзаллау булдыру*** | **1** | |
| | | | |
| 12 | **Хайваннар турында әкиятләр.** ***“Куянның ирене нигә ярык?”(Эстон халык әкияте).*** | **1** | |
| 13 | **Әкиятләрне сәнгатьле итеп сөйләргә өйрәнү.** ***“Әтәч таңда ник кычкыра?”(Монгол ха лык әкияте). Бик борынгы әкиятләрдә хайваннар арасындагы мөнәсәбәтләр, аларның тышкы күренешләре төп урынны алып тора. Борынгы әкиятләрдә геройның аңы, хәйләгә осталыгына дан җырлана. Ә әкияти вакыйгалар исә үз эченә геройның изге эшләрен, аның сәләтен, киң күңеллеген күрсәтүне максат итеп куя. Йөремсәк әкиятләр турында күзаллау булдыру.*** | **1** | |
| 14 | **Әкиятләрне сәнгатьле итеп сөйләргә өйрәнү.** ***“Юмарт дөя” (Казакъ халык әкияте).*** | **1** | |
| 15 | **Әкиятләрне сәнгатьле итеп сөйләргә өйрәнү.** ***“Табышны ничек бүләргә”?Әфган халык әкияте Африка халыклары әкияте “Сырны ничек бүлгәннәр”. Әкиятләрнең гасырлар дәвамында үсеше. Гади вакыт тасмасы: 1) бик борынгы әкиятләр, 2) борынгы, 3) бик борынгы булмаган әкияти вакыйгалар турында аңлату.*** | **1** | |
| 16 | **Үз күзәтүләреңнән, уй-кичерешләреңнән чыгып хикәяләү.** ***Л.Лерон “Мәче малае Шукбай”(Беренче танышу.Икенче танышу)*** | **1** | |
| | | | |
| 17 | **Әсәр геройларына карата үз фикереңне белдерү.** ***Л.Лерон “Мәче малае Шукбай” (Шукбай балык тота.Хат)*** | **1** | |
| 18 | **Мәсәлләр турында гомуми төшенчә бирү.** ***Эзоп “Давыл һәм кояш”, Г.Тукай “Җил илә кояш”. Мәсәлләрнең ике өлештән: хикәяләү (вакыйга) һәм моральдән (нәтиҗә, тәрбияви аңлату) торуын аңлату.*** | **1** | |
| 19 | **Мәсәлләрнең ике өлештән – сюжеттан һәм моральдән торуы.** ***Н.Исәнбәт “Ябалак белән*** | **1** | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | ***Чыпчык”,*** ***“Чыпчык белән ябалак” (Татар халык әкияте).*** | | |
| **20** | ***Т. Яхин”Карга белән төлке” Ф.Яхин “Сыр бәласе”. Мәсәлдәге хикәяләү өлешенең әкиятләрдән килеп чыгуына басым ясау. Мәсәлләрнең мораль өлешенең мәкальләр белән охшашлыгы.*** | **1** | |
| **21** | **Мәсәлләрнең төп асылын, эчтәлеген аңлау *В.Радлов “Карга хәйләсе”.* *Л.Толстой “Зирәк чәүкә”. К.Насыйри “Комсыз эт”. Мәсәл җанрының килеп чыгышы, үсеше.*** | **1** | |
| **22** | **Мәсәлләрнең тәрбияви роле *Г.Тукай “Аккош ,чуртан һәм кыскыч”.* *И.Крылов “Аккош,чуртан һәм кысла”.*** | **1** | |
| **23** | **Шигырьне сәнгатьле итеп уку. *К.Тәңрекулиев “Эшчән”гельды”.*** | **1** | |
| | | | |
| **24** | **Юмористик характердагы әсәрләрне кычкырып укыганда эмоциональ характерын чагылдыру. *И.Юзиев “ Хатасыз ничек язарга?” Р.Фәйзуллин “Ничек яхшы булырга?”.*** | **1** | |
| **25** | **Автор әкиятләрендә, халык әкиятләрендәгечә, вакыйгаларның кабатлануы, чылбыр рәвешендә тезелүе. *Ф.Яруллинның “Тылсымлы ачкыч” әкияте*** | **1** | |
| **26** | **Әкиятләрнең жанр үзенчәлеген ачыклау.*Ф.Яруллинның “Тылсымлы ачкыч” әкияте.*** | **1** | |
| **27** | **Төрле ел фасылларын чагыштырып оригиналь һәм стандарт булмаган фикерләргә кызыксыну уяту. *Г.Хәсәнов “ Май”.*** | **1** | |
| **28** | **Әдәби әсәрләрнең башка сәнгать әсәрләре белән бәйләнеше. *Г.Хәсәнов “ Май”.*** | **1** | |
| | | | |
| **29** | **Үз фикереңне әйтә белү. Дәрес-сәяхәт. *Г.Хәсәнов “ Май”.*** | **1** | |
| **30** | **Рифма төшенчәсен аңлау. *Х.Туфан “Казан” Татарстан гимны.*** | **1** | |
| **31** | **Шигырьне аңлап һәм сәнгатьле итеп уку *Ф.Кәрим “Ант”.*** | **1** | |
| **32** | **Авторның иҗат алымнары, тормышы турында күзаллау. *М.Җәлил “ Кичер,илем!”.*** | **1** | |
| **33** | **Геройның эчке дөньясын аның әйләнә-тирә дөньяны танып белүе аша күрсәтү. *Г.Ахунов “Канатлар кая илтә?.”*** | **1** | |
| **34** | **Дөньяны шагыйрьләр күзлегеннән чыгып танып белү. *Йолдыз “Спортчы шүрәле”.*** | **1** | |

КАЛЕНДАРЬНО-ТЕМАТИЧЕСКОЕ ПЛАНИРОВАНИЕ

3 класс -34 ч.

| № | Тема урока | Календарьные сроки | | Примечание |
|---|---|---|---|---|
| | | **Планируемые сроки** | **Фактические сроки** | |
| | | | | |
| **1** | **Китапханәләрдән файдалана белү.** ***Эчтәлек бите белән танышу, аңа карап, кирәкле әсәрне китаптан таба белү. Б.Рәхмәт “Иң күңелле чак”.*** | **7.09.23** | | |
| **2** | **Геройның эчке дөньясын аның әйләнә-тирә дөньяны танып белүе аша күрсәтү.** ***М.Галиев “Җиләктән кайтканда”. Кече яшьтәге мәктәп баласының дәреслектән тыш эчтәлген оештыру: өй, мәктәп китапханәләреннән файдалану. Төрле җыентыклар төзергә өйрәнү.*** | **14.09.23** | | |
| **3** | **Шигырьләрдә чагыштыруны таба белү.** ***Китапның төп өч элементын аеру: китап тышлыгы, китап төпсәсе, битләре. Китапны саклап тоту күнекмәләре булдыру.*** ***Б.Рәхимова ”Шук болытлар,батыр җил,якты кояш”,Р.Корбан “Көз нигә моңая?”*** | **21.09.23** | | |
| **4** | **Шигырьләрдә сынландыруны таба белү.** ***Шагыйрьдә чагыштыру, сынландыру, эпитет. Л.Лерон “Яңгырның ял көне”, М.Җәлил “Яңгыр” шигыре.*** | **28.09.23** | | |
| **5** | **Шигырьләр аша әйләнә-тирә дөньяны табу.** ***Р.Мингалим “Август каеннары”, З. Туфайлова “Яфрак ява.” Сәнгатьле уку күнекмәләре формалаштыру ( интонация, тон, темп саклап кычкырып уку).*** | **5.10.23** | | |
| **6** | **Әдәби әсәрләрнең башка сәнгать әсәрләре белән бәйләнеше.** ***М.Мазунов” Карап торам”, Г.Хәсәнов “Кыр казы”. Автор бирергә теләгән картинаны күзаллау. Эчтән укый белергә күнектерү.*** | **12.10.23** | | |
| | | | | |
| **7** | ***Г.Бәширов “Ана каз белән ата каз һәм аларның унике бәбкәсе”. Хикәя геройлары аларның портреты һәм характер үзенчәлекләренең башкарган гамәлләре аша чагылышы.*** | **19.10.23** | | |
| **8** | ***Авторның үз героена мөнәсәбәте. Геройларга чагыштырмача характеристика Г.Остер*** | **26.10.23** | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | ***“Серне ачты”.*** | | | |
| 9 | **Хикәя геройларының портретлары, характеры сөйләм һәм вакыйгалар аша чагылышы.** ***Н.Гыйматдинова “Сарбай”.*** | **9.11.23** | | |
| 10 | **Кешелек дөньясы һәм тылсымлы дөнья арасындагы бәйләнеш. «*Иң яхшы дару» Әфган халык әкияте, “Тылсымлы китмән» Уйгур халык әкияте. Фольклор әсәрләреннән әкиятләрне вакыт тасмасында күрсәтү (бик борынгы,борынгы,әкияти вакыйгалар )*** | **16.11.23** | | |
| 11 | **Хайваннар турында әкиятләр. “*Көрән төстәге пингвин баласы” Инглиз халык әкияте. Халык авыз иҗатының бер төре булган һәм җир йөзендәге барлык милләтләрдә дә яшәп килүче, буыннан буыннарга күчеп йөри торган хайваннар турындагы әкиятләргә карата гомуми күзаллау булдыру*** | **23.11.23** | | |
| | | | | |
| 12 | **Хайваннар турында әкиятләр. *“Куянның ирене нигә ярык?”(Эстон халык әкияте).*** | **30.11.23** | | |
| 13 | **Әкиятләрне сәнгатьле итеп сөйләргә өйрәнү.*“Әтәч таңда ник кычкыра?”(Монгол ха лык әкияте). Бик борынгы әкиятләрдә хайваннар арасындагы мөнәсәбәтләр, аларның тышкы күренешләре төп урынны алып тора. Борынгы әкиятләрдә геройның аңы, хәйләгә осталыгына дан җырлана. Ә әкияти вакыйгалар исә үз эченә геройның изге эшләрен, аның сәләтен, киң күңеллеген күрсәтүне максат итеп куя. Йөремсәк әкиятләр турында күзаллау булдыру.*** | **7.12.23** | | |
| 14 | **Әкиятләрне сәнгатьле итеп сөйләргә өйрәнү.*“Юмарт дөя” (Казакъ халык әкияте).*** | **14.12.23** | | |
| 15 | **Әкиятләрне сәнгатьле итеп сөйләргә өйрәнү.*“Табышны ничек бүләргә”?Әфган халык әкияте Африка халыклары әкияте “Сырны ничек бүлгәннәр”. Әкиятләрнең гасырлар дәвамында үсеше. Гади вакыт тасмасы: 1) бик борынгы әкиятләр, 2) борынгы, 3) бик борынгы булмаган әкияти вакыйгалар турында аңлату.*** | **21.12.23** | | |
| 16 | **Үз күзәтүләреңнән, уй-кичерешләреңнән чыгып хикәяләү. *Л.Лерон “Мәче малае Шукбай”(Беренче танышу.Икенче танышу)*** | **28.12.24** | | |
| | | | | |
| 17 | **Әсәр геройларына карата үз фикереңне белдерү.** ***Л.Лерон “Мәче малае Шукбай” (Шукбай балык тота.Хат)*** | **11.01.24** | | |
| 18 | **Мәсәлләр турында гомуми төшенчә бирү.*Эзоп “Давыл һәм кояш”, Г.Тукай “Җил илә кояш”. Мәсәлләрнең ике өлештән: хикәяләү (вакыйга) һәм моральдән (нәтиҗә, тәрбияви аңлату)*** | **18.01.24** | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | ***торуын аңлату.*** | | | |
| **19** | **Мәсәлләрнең ике өлештән – сюжеттан һәм моральдән торуы.** ***Н.Исәнбәт “Ябалак белән Чыпчык”, “Чыпчык белән ябалак” (Татар халык әкияте).*** | **25.01.24** | | |
| **20** | ***Т. Яхин”Карга белән төлке” Ф.Яхин “Сыр бәласе”. Мәсәлдәге хикәяләү өлешенең әкиятләрдән килеп чыгуына басым ясау. Мәсәлләрнең мораль өлешенең мәкальләр белән охшашлыгы.*** | **1.02.24** | | |
| **21** | **Мәсәлләрнең төп асылын, эчтәлеген аңлау** ***В.Радлов “Карга хәйләсе”. Л.Толстой “Зирәк чәүкә”. К.Насыйри “Комсыз эт”. Мәсәл жанрының килеп чыгышы, үсеше.*** | **8.02.24** | | |
| **22** | **Мәсәлләрнең тәрбияви роле** ***Г.Тукай “Аккош ,чуртан һәм кыскыч”. И.Крылов “Аккош,чуртан һәм кысла”.*** | **15.02.24** | | |
| **23** | **Шигырьне сәнгатьле итеп уку.** ***К.Тәңрекулиев “Эшчән”гельды”.*** | **22.02.24** | | |
| | | | | |
| **24** | **Юмористик характердагы әсәрләрне кычкырып укыганда эмоциональ характерын чагылдыру.** ***И.Юзиев “ Хатасыз ничек язарга?” Р.Фәйзуллин “Ничек яхшы булырга?”.*** | **29.02.24** | | |
| **25** | **Автор әкиятләрендә, халык әкиятләрендәгечә, вакыйгаларның кабатлануы, чылбыр рәвешендә тезелүе.** ***Ф.Яруллинның “Тылсымлы ачкыч” әкияте*** | **7.03.24** | | |
| **26** | **Әкиятләрнең жанр үзенчәлеген ачыклау.*****Ф.Яруллинның “Тылсымлы ачкыч” әкияте.*** | **14.03.24** | | |
| **27** | **Төрле ел фасылларын чагыштырып оригиналь һәм стандарт булмаган фикерләргә кызыксыну уяту.** ***Г.Хәсәнов “ Май”.*** | **21.03.24** | | |
| **28** | **Әдәби әсәрләрнең башка сәнгать әсәрләре белән бәйләнеше.** ***Г.Хәсәнов “ Май”.*** | **4.04.24** | | |
| | | | | |
| **29** | **Үз фикереңне әйтә белү. Дәрес-сәяхәт.** ***Г.Хәсәнов “ Май”.*** | **11.04.24** | | |
| **30** | **Рифма төшенчәсен аңлау.** ***Х.Туфан “Казан” Татарстан гимны.*** | **18.04.24** | | |
| **31** | **Шигырьне аңлап һәм сәнгатьле итеп уку** ***Ф.Кәрим “Ант”.*** | **25.04.24** | | |
| **32** | **Авторның иҗат алымнары, тормышы турында күзаллау.** ***М.Җәлил “ Кичер,илем!”.*** | **2.05.24** | | |
| **33** | **Геройның эчке дөньясын аның әйләнә-тирә дөньяны танып белүе аша күрсәтү.** ***Г.Ахунов “Канатлар кая илтә?.”*** | **16.05.24** | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| **34** | **Дөньяны шагыйрьләр күзлегеннән чыгып танып белү.** ***Йолдыз “Спортчы шүрәле”.*** | **23.05.24** | | |